| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 ноября 2024г. с.Шалты № 109

Баулы муниципаль районы Шалты авыл
җирлеге Советының «Җир салымы турында»
13.11.2020 № 5 карарына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 12.07.2024 ел, № 176-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 13.11.2020 № 5 карарына (26.02.2021 № 14, 19.12.2022 № 50, 13.06.2023 № 70, 19.10.2023 № 79 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче пунктның 2 һәм 3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, моңа индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләренең әлеге абзацында, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләре;

3) Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3%, «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып

баруы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»29.07.2017 ел, № 217-ФЗ Федераль законда каралган, әлеге абзацта күрсәтелгән һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләрдән тыш»;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач һәм чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин